ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

29.11.2024 г.Казань № 342-3/нпс-2024

2025 елга Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә иң чик максималь бәяләрне билгеләү турында

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 29.11.2024 ел, №29-ПР утырышы беркетмәсенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә максималь чик бәяләрне билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик максималь бәяләр 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.11.2024 № 342-3/нпс-2024 карарына кушымта

# Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә максималь дәрәҗәдә чик бәяләр

Бәяләр өстәмә хак салымын исәпкә алып, сумнарда

| т/с | Җир кишәрлекләре, түбәндәгеләр өчен билгеләнгән | Шәһәр торак пунктларында | Авыл торак пунктларында | Торак пунктлар чикләреннән тыш |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару | 10 869 | 10 540 | 11 423 |
| 2. | Индивидуаль торак төзелеше | 10 869 | 10 540 | 11 423 |
| 3. | Шәхси ихтыяҗлар өчен гаражлар төзү | 10 523 | 10 194 | 11 077 |
| 4. | Бакчачылык, яшелчәчелек | 10 696 | 10 367 | 11 250 |

Искәрмәләр:

1. Кадастр эшләренә максималь чик бәяләрне оештыру-хокукый формаларына карамастан Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләрен башкаручы барлык юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар куллана.
2. Бәяләр максималь дәрәҗәдә чик булып тора һәм кадастр эшләрен башкаручы юридик зат яки шәхси эшкуар карары буенча киметелә ала.
3. Кадастр эшләренең максималь чик бәяләре бер җир кишәрлегенә карата исәпләнгән һәм гражданнар (физик затлар) тарафыннан кадастр эшләренә түләгәндә кулланыла.
4. Кадастр эшләренең нәтиҗәсе булып ызанлау планы тора.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге